ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.04.2021 № 545

Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында

Бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында югары нәтиҗәләр күрсәтүче Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия составын төзергә һәм расларга (2 нче кушымта).
3. Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия турындагы Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендияләрен финанслауны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанславы исәбенә карауны тәкъдим итәргә.
5. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:
   - «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы;
   - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында»

2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 14 сентябрендәге 1124 номерлы;

- Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 28 декабрендәге 1709 номерлы;
- Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 7 декабрендәге 1518 номерлы;
- Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 8 февралендәге 136 номерлы;
- Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2014 елның 4 июлендәге 757 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 февралендәге 185 номерлы.

6. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л. Р. Яһудинга йөкләргә

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

АМР Башкарма комитетының
«545» 22.04. 2021
карарына 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында Нигезләмә**

1. Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясе (алга таба - стипендия) халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары нәтиҗәләр күрсәтүче Алабуга муниципаль районы иң яхшы спортчыларына адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлгә ашырыла (Дөнья Чемпионаты, Дөнья Беренчелеге, Дөнья Кубогы, Россия Чемпионаты, Россия Кубогы, Россия Беренчелеге).
2. Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү комиссия карары нигезендә (алга таба текст буенча - Комиссия) билгеләнә.
3. Адреслы стипендиясен ай саен финанслау Алабуга муниципаль районы Башлыгы комитетының агымдагы финанславы хисабына башкарыла.
4. Дәгъва кылучылар исемлеге Алабуга муниципаль районы спорт мәктәпләре тәкъдименнән чыгып төзелә.
5. Дәгъва кылучылар исемлеге Комиссиягә тәкъдим ителә һәм раслауга тапшырыла. Дәгъва кылучылар бер елга раслана.

   Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчылары, Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясенә дәгъва кылучылар Комиссия беркетмәсе нигезендә расланалар һәм диплом белән бүләкләнәләр.

   Стипендия алучы, спорт эшчәнлеген туктаткан, иң яхшы спортчы исемен бозучы административ гамәлләр кылган, шулай ук җинаять кылган очракта, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы тәкъдиме нигезендә Комиссия карары белән вакытыннан алда Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясеннән мәхрүм ителергә мөмкин.
6. Стипендияләр билгеләү өчен критерийлар әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелә.
7. Алабуга муниципаль районының спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр стипендия алуга дәгъва кылучылар була ала.
8. Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен алу өчен, алдагы елның 1 нче декабренә кадәр, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторына дәгъва кылучылар исеменнән түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

   - Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә дәгъва кылучы турында белешмәләр (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта);

- бөтенроссия ярышлары дипломнарының күчермәләре;
- ярышларның нәтиҗәләре турындагы беркетмәдән өземтә;
- уку урыныннан дәгъвачыга характеристика (тасвирлама);
- паспорт күчермәсе;
- Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе (ИНН);
- мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе (СНИЛС), яисә индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслый торган һәм шәхси иминият счетының иминият номеры турында белешмәләр;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта).

Тәкъдим итүне (үтенечнамәне Алабуга муниципаль районының спорт мәктәбе директоры (җитәкчесе) әзерли һәм имзалый.

9. Дәгъва кылучылар турында фикер алышу һәм аны раслау Комиссия утырышында башкарыла.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районының
иң яхшы спортчыларына Алабуга
муниципаль районы Башлыгы
стипендиясен билгеләү турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү өчен критерийлар**

| | Ярышларның дәрәҗәсе | Алган урыны | Стипендияләр күләме (олимпия һәм олимпия уеннары булмаган спорт төрләре, олимпия дисциплиналары, олимпия уены төренә кермәгән дисциплиналар), мең сум/аена | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәхси | команда белән |
| | 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Дөнья Чемпионаты | 1 | 10 000,0 | |
| | | 2 | 5 000,0 | |
| | | 3 | 3 000,0 | |
| 2. | Дөнья Беренчелеге | 1 | 10 000,0 | |
| | | 2 | 5 000,0 | |
| | | 3 | 3 000,0 | |
| 3. | Дөнья Кубогы | 1 | 10 000,0 | |
| | | 2 | 5 000,0 | |
| | | 3 | 3 000,0 | |
| 4. | Россия Чемпионаты | 1 | 5 000,0 | |
| | | 2 | 4 000,0 | |
| | | 3 | 3 000,0 | |
| 5. | Россия Кубогы | | 5 000,0 | |
| 6. | Россия Беренчелеге | 1 | 5 000,0 | |
| | | 2 | 4 000,0 | |
| | | 3 | 3 000,0 | |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районының
иң яхшы спортчыларына Алабуга
муниципаль районы Башлыгы
стипендиясен билгеләү турындагы
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә дәгъва кылучы турында белешмәләр

| Дәгъва кылучының Ф.И.А.и. | (чч.мм.гг.) Туу датасы | Адресы | Спорт мәктәбенең аталышы | Дәгъва кылучының куйган казанышлары турында кыскача белешмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Өстәмә белем бирү
учреждениесе җитәкчесе
______________________________(Ф.И.А.и.)
(Имза)
МУ

Искәрмә:
1. Ярышларда катнашуы хакында тасвирламада кыскача күрсәтергә.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районының
иң яхшы спортчыларына Алабуга
муниципаль районы Башлыгы
стипендиясен билгеләү турындагы
Нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия составы**

| Ф.И.А.и. | Вазифасы |
|---|---|
| Яһудина Л.Р. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Гарифуллин И.И. | -Алабуга муниципаль районының «2 нче спорт мәктәбе» МБУ директоры, комиссия рәисе урынбасары |
| Бухарева О.И. | - «Спорт корылмалары дирекциясе» МАУ инструктор-методисты, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Садыйкова Э.И. | - Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Шалаумова Н.П. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гарифуллина Э.Ю. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр белән идарә итүчесе |
| Глазистов А.В. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы мөдире |
| Затиев Ю.А. | Алабуга муниципаль районының «1 нче спорт мәктәбе» МБУ директоры |

| | |
|---|---|
| Мөхетдинов М.Р. | Алабуга муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ директоры |
| Немтырев А.М. | - Алабуга муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» МБУ директоры |

АМР Башкарма комитетының
«545» 22.04. 2021
карарына 3 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия турында Нигезләмә**

1 Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия (алга таба Комиссия) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычы - Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә дәгъва кылучының материалларын, документларын карау.

4. Комиссия - комиссия рәисе, аның урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә. Комиссия эшчәнлеге белән аның рәисе җитәкчелек итә.

5. Комиссия утырышлары агымдагы елда кергән материаллардан чыгып уздырыла. Комиссия утырышын Комиссия рәисе яисә, ул булмаган очракта, комиссия рәисе урынбасары алып бара.

6. Агымдагы елның 1 нче февраленә кадәр комиссия стипендия бирү турында кабул иткән карарын җибәрә.

7. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса тулы хокуклы санала. Карала торган мәсьәләләр буенча Комиссия карары утырышта катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия карары белән килешмәгән Комиссия әгъзасы Комиссия карарына язма рәвештә аерым фикерен теркәргә хокуклы, ул Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.